**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.01.2015 № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары карарына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, "Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2012 елның 06 августындагы 1085/1 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын расларга:

1.1. Торак урынын, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.2. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.3. Торак шартларын социаль түләүләрдән файдаланып яхшырту теләген белдергән гражданнар исемлекләренә кертү һәм авыл җирендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

2. Әлеге карарны һәм кушымта итеп бирелә торган административ регламентларны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үз көченә кергән вакыттан алып "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2015 елның 19 декабрендәге 1063 номерлы карарны үз көчен югалткан дип санарга.

Җитәкче А.К. Габдуллин